СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның ... июленнән бирле чыга | №109 (7882) | 12 сентябрь, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен

Сессиядән соң... очрашу

—Районда бизнес белән шөгыльләнүче утызлап кеше бар,—дип башлады сүзен халык депутатларының район Советы рәисе Х. Х. Морадыймов.—Болар чын мәгънәсендә эшкуарлар. Киләчәк—алар кулында.

Әлеге сүзләр район Советының бишенче сессиясеннән соң, фермерлар һәм кооператив рәисләре белән очрашу вакытында әйтелде. Анда брокер фирмалары белән элемтәләр урнаштыру, район кооператор-фермерларының ассоциациясен төзү, яклау фонды булдыру, эшкуарларның санын арттыру өчен шартлар тудыру...хакында эчкерсез сөйләшү булды.

Чөгендер басуларында эш кайный

Икенче икмәк

«Чирмешән» колхозының 137 гектар мәйдан биләгән татлы тамыр плантациясе бу көннәрдә машина-трактор шавына күмелде. Икенче икмәкне әрәм-шәрәм итмичә, югалтуларсыз җыеп алу өчен удар эш башланды.

Биредә МКК-6 чөгендер казыту комбайнчылары Җәмил Хәсәнгатин, Рәшит Фәсхиев зур тырышлык куеп һәм фидакарьлек үрнәге күрсәтеп эшлиләр.

БМ-6 яфрак урдыру комбайннарында исә Фоат Вәлиәхмәтов, Фоат Гыйләҗев та үз эшләрен зур җаваплылык хисе һәм намус белән башкаралар.

Чөгендер ташуда Норлат автотранспорт предприятиесеннән ярдәмгә килгән КамАЗ машинасы шоферлары Ирек Яруллин, Ринат Шакиров, Владимир Мокеев өлгерлек күрсәтә.

И. ЗӘЙНУЛЛИН.

Чимал озатабыз

Муса Җәлил исемендәге колхоз. Хуҗалыкта 198 гектар фабрика максатларында чөгендер игелә. Хәзер биредә бөтен куәтенә чөгендер алу бара. Фәрит Фатыйхович Хәсәншин, Исламгәрәй Шәйхуллович Сатдаров, Хатыйп Хөсәенович Гайнетдинов җитәкчелегендәге механикалаштырылган звено члениары аяз көннең һәр мөмкинлеген тулысынча файдаланырга тырышалар. Чөгендерче апайлар хезмәтенә дә тел-теш тидерерлек түгел. Чыгарылган чималны өемнәргә ташуда Ирек Кәлимуллин, Илдал Нуретдинов, Әхәт Гобәйдуллин, Гомәр Вәлиев бик өлгерләр. Алар ук чөгендер яфрагын силослау өчен дә ташыйлар. Заводка озатуда исә шоферлар Фәрит Мингалимов, Фәнил Җаббаров, Расыйх Җамалетдинов, Фатыйх Шәгехетдинов, НУРБ дан беренчә ел рәттән хуҗалыкка ярдәмгә килүче Александр Игнатьев, Рөстәм Салахов, Рифкать Бикчуров намуслы хезмәт куялар.

Уртак тырышлык белән хуҗалыктан заводка 9 мең центнер чимал озатылды инде.

Г. ЯРУЛЛИН,
бухгалтер.

Татлы тамыр алына

Мичурин исемендәге колхоз. Беренче бригадада 140 гектар мәйдандагы чөгендернең 20 гектары, икенче бригадада 100 гектарның 22 гектары алынды.

Беренче бригада РКС-6 комбайнчылары Анатолий Аркадьевич Иванов, Геннадий Сергеевич Петров, икенче бригадада Анатолий Михайлович Кульметьев, Дмитрий Яковлевич Яргунов аяз көннең һәр минутын отышлы файдаланып эшлиләр.

БМ-6 яфрак урдыру комбайнчылары Александр Иванович Бочкарев, Станислав Валерьянович, Николаев, Дмитрий Яковлевичның улы Вячеслав Дмитриевич Яргунов, Аркадий Леонтьевич Кузьмин да вакыт белән исәпләшмичә эшлиләр.

СПС-4,2 агрегатында Юрий Никитович Васильев аеруча өлгерлек күрсәтә.

Норлат шикәр заводының кабул итү пунктына чөгендер ташучы шоферлар—Андрей Васильевич Гаврилов (КамАЗ машинасы), Владимир Витальевич Тимофеев (ЗИЛ-130), Павел Михайлович Кузьмин (ГАЗ-53) эштә өзеклек тудырмыйлар.

Чөгендер алу дәвам итә.

Р. ГАВРИЛОВА,
экономист.

КҮМӘК КӨЧ БЕЛӘН

«Большевик» колхозы. Биредә татлы тамыр 225 гектар мәйдан били. Бу көннәрдә күмәк көч һәм уртак тырышлык белән аның 40 гектары алынды.

КС-6 чөгендер казыту комбайнчылары Виталий Туймешев һәм Николай Васильев быел да зур җаваплылык хисе белән эшкә тотындылар. БМ-6 яфрак урдыру комбайны белән Виталийның энесе Владимир да басуга чыкты. Биредә шулай ук Юрий Парфенов та эшли. Юрий Туймешев исә тракторга тагылган СПС-4,2 агрегаты белән чөгендер төяүдә зур өлгерлек күрсәтә.

Татлы тамырны басудан КамАЗ шоферы Анатолий Лизратов, ГАЗ-53 шоферы Владислав Пайдуганов (җәйге чорда ул комбайннан ындыр табагына ашлык ташуда районда беренче урынны алган иде) ташып торалар.

В. ПАРУКОВ,
колхоз рәисенең урынбасары.

Владимир Васильевич Уткинның һөнәрен рәсеменнән үк чамалап була— газ белән эретеп ябыштыручы ул. Бу һөнәрнең нечкәлекләренә төшенеп җиткән Уткинның салган җөйләре һәрчак ышанычлы, ныклы була. 53 нче СМУ-да ул җөй салган торбаларны бергә сузсаң күпме чакрымнарга сузылыр икән. 15 еллап эшләү дәверендә Владимир Васильевич коллективның ихтирамын шулай тырыш хезмәте белән яулады. Ул коллективның җәмәгать тормышында да актив катнашып килә: техника куркынычсызлыгы буенча инспектор, профсоюз комитетының хезмәт бәхәсләре буенча комиссия члены да.

Рәсемдә: В. В. Уткин эш вакытында.

Күркәм уңыш

Норлат разведка бораулавы идарәсе коллективы үз алдына куелган максатка ирешү өчен зур тырышлык куеп һәм фидакарьлек үрнәге күрсәтеп эшли. Агымдагы елның сигез аенда ул планда каралган 111 мең 700 метр урынына 118 мең 420 метр тирәнлектә бораулау эшләре башкарды.

А. А. Захаров (11 мең 500 метр урынына 15 мең 045 метр), М. М. Хәсәншин (14 мең 500 метр урынына 17 мең 177 метр), В. В. Фомин (14 мең 800 метр урынына 15 мең 668 метр), Р. В. Мингалимов (12 мең 900 метр урынына 14 мең 123 метр), Ю. Г. Газизов (10 мең метр урынына 11 мең 73 метр), разведка скважиналары буенча М. Ф. Ананьев (7 мең метр урынына 9 мең 208 метр) җитәкчелегендәге бригадалар планнарны уңышлы үтәп аеруча күркәм уңышларга ирешәләр.

С. ВАСИЛЬЕВА,
Норлат разведка бораулавы идарәсе экономисты.

◆ *Газетага язылу көндәлеге*

Минем тәкъдимем

«Дуслык» газетасы минем күңелгә кече яшьтән үк сеңеп калган. Ул «Октябрь колхозчысы» чагыннан ук безнең гаиләнең якын дусты, киңәшчесе. Һәм бер ел да калдырмыйча аны алдырып, кызыксынып укып барабыз. Яраткан газетабызга быел да язылдык. Анда илдәге, җөмһүриятебездәге мөһим вакыйгалар һәм районыбыз тормышы тулы чагылдырылып килә. Миңа шулай ук авыл хезмәтчәннәренең эшләре, тормышлары турындагы язмалар бик ошый. Ә китапханәче буларак, мин газетада әледән-әле бастырылып килә торган якташларыбызның әдәби әсәрләре, шигъри тәлгәшләрен бик яратып укыйм. Аларны китапханәдә укып, китап укучылар белән дә тикшерәбез, фикер алышабыз, киләчәктә дә үзебезнең җирле талантларга игътибар тагын да артыр дип ышанабыз. Бу уңайдан минем газета редакциясенә бер тәкъдимем бар. Газетаның күп урынын атналык телевидение программасы алып тора. Ул бит аерым да чыгарыла, республика газеталарында да басыла. Ә бер табаклы район газетасы өчен, минемчә, ул артык. Бу урынга кызыклырак материаллар, файдалы киңәшләр бастырсагыз, газета отар гына, тагын да җанланып китәр иде.

Гөлсирә УСМАНОВА,
Кизләү авылы китапханә мөдире.

Тырышып эшлиләр

Сугару-киптерү системаларын эксплуатацияләүнең Норлат идарәсе коллективы агымдагы елның 1 сентябренә 109 мең сумлык мелиорация эшләре, «Родина», «Кондырча», XXI партсъезд исемендәге, «Правда» колхозларында планнан тыш юл күтәрү бәрабәренә 60 мең сумлык эш башкарды.

Биредә Т-150 тракторчысы Николай Анатольевич Левинов, Т-130 тракторчысы Исхак Идрисович Мәүлетов, ДТ-75 тракторчысы Вячеслав Юрьевич Степанов үзләрен аеруча тырыш кеше буларак таныттылар. Җәй айларында «Таң» колхозына ярдәмгә килгән һәм комбайнда хезмәт куйган Нурислам Нуруллович Вильданов, шулай ук ЗИЛ-150, ГАЗ-53 машинасы шоферлары Ирек Салихович Җәлалов, Ринат Галимҗанович Вәлимөхәммәтов турында да гел җылы сүзләр генә әйтәсе килә.

А. МУСИНА,
экономист.

Әйбәт нәтиҗәләргә ирешәләр

«Комбайн» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәтчәннәре арасында мактауга лаек алдынгылар байтак. Шундыйлардан беренче товарлыклы-сөтчелек фермасында профилакторий группасындагы 20 көнгә кадәрге бозауларны караучы Маһинур Кәримова белән Хания Семованы атарга була. Алар үз группасындагы бозаулардан 868-әр грамм уртача тәүлеклек үсеш алуга ирешәләр.

Икенче товарлыклы-сөтчелек фермасы арендачылары Әмир Шәрәпов, Илсур Сафин, Фәнис Нуруллин да әйбәт җенә эшләп киттеләр. Армиядән кайтып икенче елларын хезмәт куючы бу егетләрнең хәзергә үз карамакларындагы бозаулардан алган уртача тәүлеклек артымнары—604 әр грамм.

Колхоз буенча исә уртача тәүлеклек артым 610 грамм тәшкил итә.

Г. ГАЙНЕТДИНОВ,
профсоюз комитеты рәисе.

Бүгенге санда

1. КЫР ЭШЛӘРЕ КӨНДӘЛЕГЕ.
2. «ХӘТЕР» ПОЧТАСЫ.
3. ИГЪТИБАР: ЯҢА ГАЗЕТА.
4. «02 ХӘБӘР ИТӘ».

Миллионнар әйләнеп кайтмады

«ХӘТЕР» почтасы

Утызынчы еллар башында Норлат тимер юлның ике ягына урнашкан гадәти поселок иде. Бер яктан агачтан салынган район үзәге, линиянең икенче ягында—Линейная, Куйбышев урамнарында тимер юлчылар яши. Ул чактагы тормыш бүгенгесенә күп охшаш—товар «дефицит», чиратлар озын иде. Әмма ул чорда базар бар, крестьян азык-төлек, яшелчә, терлеген шунда китерә иде. Ул елларга хас тагын бер момент—һәр ике якта язын-көзен үтеп йөри алмаслык балчык, җыелган су була торган иде.

Кән итү авыр булса да, халык күтәренке күңел, киләчәккә ышаныч белән яшәде. Тимер юлчылар клубында тантаналы бәйрәмнәрдә халык залга сыймады—өлкән буыннар политика белән кызыксынды. Ул елларда ораторлар язганны укымыйча гына, аңлаешлы итеп чыгыш ясый иде. Аларны зур игътибар белән тыңладылар һәм трибунадан хәбәр ителгән һәр сүзгә ышандылар.

Ул чорда норлатлылар яратып тыңлый торган ораторларның берсе КПСС райкомының беренче секретаре Матвеев иде. Ул күп яктан сәләтле шәхес: акыллы, тактлы, эрудицияле һәм иң мөһиме—аралашучан, үз кеше: очрашу өчен бер атна алдан язылысы, сәгатьләп кабул итүен көтәсе түгел. Еш кына докладтан соң тыңлаучылар аны урап ала, сораша, озак тоткарлый торган иде. Соңрак җитәкчеләр һәм гади халык арасында мондый мөнәсәбәтләр акрынлап юкка чыкты һәм бәйрәмнәргә йөрү теләге сүрелде, мәҗбүр итәргә туры килде.

С. М. Кировны үтергәннән соң илдә башланган репрессияләр шаукымы безгә дә тиз килеп җитте. Бервакыт поселокта хәбәр таралды: элекке (шулай дим, чөнки ул безнең районнан киткән иде инде) беренче секретарь Матвеев халык дошманы буларак кулга алынган.

Үзәк матбугат безне моңа әзерләгән иде инде: троцкийчылар, корткычлар, диверсантлар, халык дошманнары, төрле уклончылар турында радио һәм газеталар чаң сугып тордылар. Ул моментка кадәр бу абстракт рәвештә кабул ителде: барысы читтә, бездә түгел иде, ә бу юлы үз кешебез, җитмәсә, гади кеше түгел, районда беренче кеше булып чыкты. Гаҗәпләнергә, баш ватарга урын бар иде биредә. Ул чакта радио, газеталарга ышаныч зур иде, булган хәлгә дә ышандык. Кулга алынган—димәк, дошман: гаҗәбе—йөзен ничек оста яшерә белгән.

Шул ук вакытта диярлек депо филиалы начальнигы Грудинин һәм район больницасында врач булып эшләүче аның хатыны кулга алынды. Моның сәбәбе ул вакыт өчен бик җитди иде: чыгарылыш кичәсендәге фоторәсемдә (ул Мәскәү транспорт инженерлары институтын тәмамлаган) • Грудинин тимер юл министры урынбасары, тарихта яхшы мәгълүм Пятаков белән янәшә баскан: аларга, ягъни троцкийчыларга багышланган процесс тәмамланган гына иде әле. Чекистларның логикасы гади: рәсемдә янәшә баскан—дуслар, димәк, фикердәшләр...Ә Грудининнарның шуннан соңгы язмышы бүген дә билгесез.

Ул вакытта ил бизгәк тоткан шикелле тоелды: яңадан-яңа троцкийчылар, корткычлар, шпионнар ачыла торды. Атна саен диярлек депо цехларының берсендә станция эшчеләрен һәм хезмәткәрләрен җыялар иде. Тынып калган халык алдында партбюро секретаре чираттагы процесслар турында ТАСС хәбәрен укый. Аннан эшче активистларга сүз бирелә: халык дошманнарына бердәм рәвештә хурлык тамгасы суктылар, аларга иң югары җәза бирүне—атуны таләп иттеләр. Кул чабулар җыелышта катнашучыларның бердәм теләген чагылдырды. Шул хакта алдан хәзерләгән резолюция кабул ителеп райкомга җибәрелә килде. Берәү дә шик күрсәтмәде, барысы да нәфрәтен белдерергә ашыкты.

Мәскәү процесслары ишәйгән саен халыкны үз язмышы өчен курку били барды. Радио һәм матбугат уяулыкка чакырды: дошман йокламый, ул—безнең арабызда. Кешеләрнең бер-берсенә ышанычы калмады, һәркем шикләнде: кем белә... Якташларымның ул шикләре «чынга аша» торды.

Машинистлар Н. Ф. Томский һәм С. А. Галькевич эштә вак саксызлыкка юл куйганнар иде. Бөтен җирдә курку һәм шикләнү шартларында әләкче хезмәттәшләре (алар һәр службада бар иде) тиешле органнарга хәбәр иткәннәр: корткычлар. Аларны кулга алдылар. Николай Филиповичның дүрт бала, Станислав Адамовичның алты баласы бар иде. Халык дошманы гаиләсе үзеннән үзе законнан тыш дип игълан ителде: квартираларыннан чыгардылар. Кая барырга? Властьларга ярдәм сорап бару файдасыз. Таныш-белешләр йөз чөерә, читләшә, үзләре һәм якыннары өчен куркалар.

Моның белән генә чикләнми әле. Мәктәп тә читтә калмый. Томскийны кулга алуга берничә көн үткәч тә, озын тәнәфестә пионер линейкасы игълан ителә. Барабан кагып аңа пионер байрагын алып керәләр. Политик моментта сизгерлек күрсәтүче пионервожатый әмер бирә: «Борис Томский! Отрядтан чык!».

Көчле, тантаналы яңгыраган тавыш астында Борис алга чыга. Халык дошманы улы булганы өчен ул Ленин исемен йөрткән пионер оешмасыннан чыгарыла. Үле тынлыкта аның галстугын салдырып алалар. Күп укытучылар күзләрен яшерә, пионерлар бу иптәшләреннән йөз чөерә.

Ә тормыш дәвам итә. Иртән безне популяр дикторларның күтәренке тавышы, аһәңле музыка, политик җырлар йокыдан уята. Төнге курку юкка чыга, әзерләп куйган юл капчыклары (эчендә сохари, тәмәке һәм җылы киемнәр) урынында кала. Тимер юл клубында чираттагы мавыктыргыч фильм күрсәтелә. Анда кешеләр бөтенләй икенче төрле яши: хезмәтләреннән тәм табып эшлиләр, яраталар: реаль тормыштан бөтенесе аермалы. Шуңа тамаша залыннан чынбарлыкка кайтасылары килми. «Барлык халык дошманнарын юк итәрбез дә, яңа, бәхетле тормышта яши башларбыз»,—дип уйлыйлар алар.—Ә әлегә телне тешләргә, түзәргә кирәк, югыйсә...»

...Өлкән буын кешеләре Иннокентий Семенович Семеновны хәтерлидер әле. Әйбәт агроном иде. Колхозда бер җыелышта четерекле сорау белән аны «тозакка» эләктерәләр: «Кайсы илнең авыл хуҗалыгы техникасы әйбәтрәк—безнекеме, Германиянекеме?» Семенов «политик моментны» исәпкә алмый, соңгысына өстенлек бирә. Бер-ике көннән аны урын өстеннән торгызып алып китәләр: «патриотизм хисен үзгәртү өчен» ерак җирләргә җибәрәләр. «Өйрәнү» ун елга якын сузыла. Авыру, рухи яктан сынган хәлдә кайта Иннокентий Семенович туган ягына. Үлгәнче анда күргән михнәтләре өчен түгел, бер дә юкка Сталин лагерьларында үткәргән гомере өчен сызлана: реабилитация өчен эшен карый башлагач, анда хөкем турында берниндн карар да булмый. Элементар хокукы да юклыгын ачык күрсәтә бу һәм шулай хөкем ителмичә озак еллар каторга хезмәтен, андагы кыйнау, ачлыкны башыннан кичерә.

Яки тагын бер фаҗигале язмыш. Октябрь район халык судында яклаучы булып Александр Дмитриевич Нечаев эшләде. Белемле, һәрьяклап эрудицияле, төрле яктан җәлеп итәрлек шәхес иде. Район властьлары җәберләгән авыл халкы яклау һәм хакыйкать эзләп аның янына киләләр һәм аны таба торганнар иде. Александр Дмитриевич ихтирамлы: зур стажлы коммунист, гражданнар сугышында катнашкан кеше иде. Абруеннан, дәүләт льготаларыннан файдаланып тыныч кына яшәп ятарга да мөмкин булыр иде, ләкин ул алай яши алмады, гаепсез эзәрлекләнүчеләрне яклап һәрчак «сугыша» торган иде. Власть ияләренә, табигый ки, бу ошамады—элекке партизанның язмышы хәл ителде. Хакыйкатьне яклаучы күп еллар үткәч, Бөек Ватан сугышыннан соң гына әйләнеп кайтты. Ул бөтенләй икенче кеше, Берия лагерьларында аны «алмаштырганнар» иде:хакыйкать эзләп бүтән көрәшкә чыкмады, аны бу теләгеннән биздергәннәр иде. Сүз уңаеннан шуны әйтик, ул Бөек Ватан сугышының күренекле полководецы, булачак Советлар Союзы Маршалы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое К. К. Рокоссовский белән бергә утырган булып чыкты (аны 30 нчы еллар азагына кулга алалар һәм сугыш башлану алдыннан аклыйлар, иреккә чыгаралар).

Ул елларда психоз, «халык дошманнарын» эзләү абсурдка кадәр барып җитте. Бервакыт мәктәпкә килгәч хезмәттәшләремне гадәти булмаган шөгыль өстендә очраттым. Алар лупалар белән коралланып, дәшми-тынмый дәфтәр тышлыгындагы рәсемнәрдән нидер эзлиләр иде. Дошманнарны аеруча «тырышып» эзләүчеләрнең кайберләре Л. Н. Толстой сакалында свастикага охшашлык, А. С. Пушкин портретында Троцкий белән уртаклык таптылар...Бу акылсызлык классларга да күчте: ул көнне укучылар да, дәресне онытып, полиграфия промышленностендагы троцкийчыларны эзләү белән мәшгуль булдылар. Тулы бер төргәк шундый дәфтәрне мәктәп парторгы райкомга илтеп тапшырды. «Кулга алынган» дәфтәрләрнең шуннан соңгы язмышы билгесез калды.

Бу язмамда мин үзем күреп белгән кайбер кешеләрнең язмышын гына тасвирладым. Шул еллар корбаннарыннан тагы берничә кешене беләм. Депода «халык дошманнары» аеруча күп булып чыкты. Кулга алынучылар арасында депо филиалы начальнигының чираттагысы—Щукин, машинист Валавин, электростанция эшчесе Крылов, узел партбюросы секретаре Цибульников һәм башкалар да булды.

Алда санап үтелгәннәрнең күбесенә «бәхет елмайды». Томский һәм Галькевич 2 елдан артык утыргач гаиләләре янына кайттылар. Анда күргәннәре турында авыз ачып ник бер сүз дәшсеннәр. Ә башкалары «даһи юлбашчыбыз» үлгәч кенә моңа ирешәте. Сәламәтлекләре какшаган бу кешеләрдә «якты киләчәккә» өмет чаткысы калмаган иде инде.

Сталинизмның кешеләргә юк итү механизмы бүген һәркемгә мәгълүм, язып яңалык ачасы юк. Ләкин мин миллионнарча гаепсез корбаннарга китергән бу тарихка кире кайтып карауны нигезле саныйм: халыкта ул чордагы курку хисе әле дә саклана. Без әле дә шуның әсире. Сталин үзе үлсә дә, шул системага кире кайтуга омтылыш саклана әле. Август вакыйгалары—фетнә шуңа омтылыш түгел идемени?!..

Безнең милли аңыбыз акрынлап булса да баш калкыта, демократия, ирек күңелләрдә тамыр җәя. Ләкин аерым регионнарда ул милли характер ала. Ә бу милли битлеккә төренгән сталинизм түгелме соң? Шуңа күрә язмамны Юлиус Фучикның: «Кешеләр, сак булыгыз!» дигән сүзләре белән төгәллисе килә. Минемчә, бу кисәтү сүзләре бүгенге болганчык, алдан күп нәрсәне ачыклый алмаган заманга бик тәңгәл килә шикелле.

В. ПОСЕЛЕННОВ.

Норлат шәһәре.

Сессия үтте—икенче көнне су бетте

Без, Нефтьчеләр урамында яшәүчеләр су юклыктан ел әйләнәсенә интегәбез. Дөрес, быел 1 май, 9 май бәйрәмнәре көннәрендә, район Советы сессиясенә кадәр 1 сентябрьдән 6 сентябрьгә кадәр су биреп алдылар, икенче көнне ул да бетте. Су бирүнең хикмәтен без соңыннан гына аңладык: сессиядә су мәсьәләсе каралган икән.

Гомумән, бу урамда начальниклар тормаганлыктанмы, юлларыннан кереп чыгып булмый, казылып ватылып беткән. Моннан 15 ел элек шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе мәрхүм Г. Мусин күрсәтмәсе белән куелган лампочкалар да янганнар, урамда караңгы, балаларга уйнар өчен бер генә балалар мәйданчыгы да юк. Хәзерге вакытта төп юлда шәхси гаражлар төзергә тотындылар. Ә бит сайлаулар алдыннан район Советына депутатлыкка кандидат шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе М. Фәрхахов белән очрашу вакытында ул нәрсәләр генә вәгъдә итмәде. Вәгъдәсен үтәгәне юк. Киресенчә, булганнары юкка чыга.

Шәһәр Советы башкарма комитеты безнең зарыбызны ишетсен иде.

З. МӨХӘММӘТҖАНОВА
һәм 11 имза.

Илшат та авыл малайлары шикелле ялан тәпи йөгереп үсте. Яшьтәшләре кебек ул да техника тирәсендә буталды, аның серләрен белергә тырышты. Армия сафларында хезмәт итеп кайтуына да өч ел вакыт узды. Һәм балачактан мәхәббәте тамыр җәя башлаган тракторчы һөнәрен үз итте.

Язгы һәм көзге чәчүдә булсынмы, җирне туңга сөрү эшләрендәме, Илшат үзенә җиткерелгән норманы арттырып үти.

Рәсемдә: «Знамя Октября» колхозы тракторчысы И. М. Рәхмәтуллин.

ҮГЕТЛӘП ТОРАСЫ ЮК

—Шамилнең комбайны әллә нәрсәгә чыгымлап тора әле быел. Юкса, бер эшкә тотынса, җир җимертә торган иде әле ул да...

Чөгендерче апайларның сүзе хак. Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә механизаторы Шамил Яруллин районда иң яхшы чөгендер игү остасы буларак күптән мәгълүм. Иң алдынгы ысулларны да беренче буларак ул кулланды, уңышны да ифрат мулдан алган еллары аз түгел—кыскасы, тәҗрибәсе дә, белеме дә сәбханалла гына. Тик ни диярсең—быел звено һич кенә дә көйле эшләп китә алмый бит! Юкса, чөгендер игү техникасын әзерләү, ел үзенчәлекләреннән чыгып аны оештыру буенча район семинары дә биредә әйбәт кенә үтте. Хәер, алдан ук егетләргә кәефсез язмыш юрамыйк! Звено членнары Нәфис Бикбаев, Газиз Сабиров, Талип Мусин, Зәйдулла Әхмәтсафин нинди шартларда да сер бирә торган егетләр түгел, көндәшләреннән калышмаска тырышалар. Хәер, көндәшләр сүзе туры килеп бетәр микән бу очракта? Дөресрәге, ярышташлар, дуслар. 10 елга якын инде Шамил Яруллин белән Зәйдулла Мөхәммәтов звеносы хуҗалыкның 190 гектарлы бөтен чөгендер җирен үз кулында тота. Ярышып, шул ук вакытта киңәшеп тә эшләргә гадәтләнгәннәр инде алар. Бүген Яруллин звеносының калышуына ник бер шатлану-сөенү галәмәте күренсен соңгылары йөзендә. Чөнки беләләр: көннәр әйбәт торганда, уңышны җыю, заводка озату хәерле! Әнә беренче көннәрдә һава нинди әйбәт иде. Мөхәммәтов егетләре сыдырып эшләделәр. БМ-6А да Солтангәрәй Мөхәммәтов, чималны чыгаруда Юныс Шәфиев, чистартуда Фәрит Әһлиуллин, Юныс Мөхәммәдиев кичке караңгыга кадәр хезмәт куйдылар. Алар карамагындагы 9 ар кешелек 4 звено апайлар чималны чистартып, заводка озатып тордылар. Апайларны да эшкә өйрәтәсе түгел. Бикә Гыйльманова, Фатыйма Кәбирова, Миннеруй Мәхмүтшина, Хәнифә Мортазина, Малия Зөлкәрнәева инде пенсия яшендәге кешеләр. Гомер буе кышын терлекчелектә эшләгәннәр алар, җәйләрен чөгендер үстергәннәр. Хәзерге кебек кыска вакытлы ялда чөгендерче язмышындагы әллә нинди катлаулы, авыр елларны искә алгалыйлар. Ул күтәрткеч белән чөгендер алу дисеңме, көрәк белән казумы—һәммәсе дә үтте алар башыннан. Кулдан чималны машинага төяү тагын! Кулбашлары калмый иде туң чөгендерне . бәрә-бәрә, ә хәзер Минислам Мөхәммәтов белән Шәмсетдин Мусин СПС-4,2 автотөягече белән бер кисәк арада машинаны җәлт итеп тутыра да куя. Шоферлар Рафик Мөлеков, Минхан Абдуллин, Рәшит Мифтахов, Илгиз Сиражев, Биҗан Мөхәммәтҗанов, Равил Мөхәммәтов шунда ук заводка юл тоталар. Әлегә чөгендернең сыйфатына тел-теш тидерерлек түгел иде. Ә чөгендернең сабагын 4 машина җәйге лагерьга ташып тора—малларга бер дигән азык бит!

Чөгендер чоры кешеләрне һәр елны ничектер җыйнаклатып җибәрә, бергә туплый. Уртак хезмәт галәмәтедер ул. Шулай булмаганда, мондый мәшәкатьле эшне җиңеп чыгам диярге дә юк. Соңгы елларда табигате дә әллә нишләп куйды бит аның. Узган елны кара инде син. Ул уңды чөгендер, ул матур булып үсеп өлгерде дә—китте яңгыр, китте боз—җир өстенә ничекләр итсәң дә керерлек калмады. Югары Норлатлылар нәкъ Себерне буйсындырган кебек тездән бозлы су, пычракта җыйдылар уңышны. Быел, шөкер, участоклар да алай зур түгел, җире дә тотрыклырак булырга ошый. Дөрес, уңышы узган елгыдан байтакка кайтыш. Шулай да барын исән-имин җыеп тапшырырга иде. Инде хуҗалык җитәкчелеге шартларны да тудырмады түгел. Механизаторларга 2 тапкыр кайнар аш килеп тора, теләүчеләргә көн азагында саунага кереп юынырга була. Шулай булып торганда, ничек хезмәтеңне кызганырга мөмкин ди? Өстәвенә, әле уңыш җыю турында сүз барганда. Югары Норлат авылы уңганнарын бу яктан үгетләп торасы юк.

...Кыска вакытлы ял тәмамланды, басуда эш башланды.

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

«ДУСЛЫК»

● Газета—синең киңәшчең дә, дустың да

Мини-әңгәмә

Район газетасына язылу ничек бара? Шул хакта кызыксынып, без элемтә бүлекчәләренә шалтыраттык һәм сораулар белән мөрәҗәгать иттек.

Фома элемтә бүлекчәсе.

СОРАУ: Авыл халкы «Дуслык»ка теләп язаламы?

Миңлегөл Әнвәровна Гыйниятуллина, элемтә бүлекчәсе начальнигы:

Хәтта быел үгетләп йөрергә дә туры килмәде. Кешеләр аңлы рәвештә үзләре теләгән җирле вакытлы матбугатка язылдылар. Иң беренче чиратта, әлбәттә, «Дуслык» газетасына. Ул районыбызның көзгесе, аннан үзебезгә кирәкле мәгълүматларны алырга була, диләр. Аннары, татарча газеталарга да караш үзгәрде. Әйтик, шофер Вәзыйх Гомәров 85 сумлык газета-журналга язылды. «Дуслык», «Социалистик Татарстан» газеталарын, «Салават күпере», «Сөембикә», «Ялкын» кебек журналларны алдырачак. Зирекле авылыннан Рәстәм Мотыйгуллин да 105 сумлык басмага язылды. Мондый уңай үзгәрешләрне күреп сөенәбез генә.

СОРАУ: Район газетасына язылу тиз арада төгәлләнәчәкме?

М. Ә. Гыйниятуллина: Бүгенге көндә безнең элемтә бүлекчәсендә 335 данә «Дуслык» газетасы исәпләнә. Фомада инде газетага язылу төгәлләнеп бетте, Биккол һәм Зирекле авыллары гына калдылар.

СОРАУ: Иң яхшы почтальоннар дип кемнәрне саныйсыз?

М. Ә. Гыйниятуллина: Бикколдан Халидә Әһлиуллина, Зирекледән Зәйнелгарәп Шәрәфетдинова, Фомадан Венера Фатыйхова, Әлфия Зәйнуллинаны.

—Эшегездә уңышлар телибез.

М. Ә. Гыйниятуллина. Рәхмәт.

(Әңгәмәнең ахыры 4 нче биттә).

Балаларыбыз өчен

Безнең музыка мәктәбе базасында 3 ел рәттән сәнгать мәктәбе (җитәкчесе —Ә. М. Камалетдинов) эшләгән иде. Үткән ел ул эшләүдән туктады. 4 елга исәпләнгән курс шул рәвешле өзелде, ә балалар үзләре теләп йөргән мавыгуларыннан мәхрүм калдылар.

Менә янә дә яңа уку елы башланды. Әлеге сәнгать мәктәбендә шөгыльләнергә теләүче балалар да шактый җыела. Без —ата-аналар җитәкченең үзе белән сөйләшеп караган идек, ул нигездә каршы түгел. Әмма... шөгыльләнү өчен урын юк икән. Изге нияттән, ныклап торып эзләп караганда, әлеге кечкенә генә остаханә өчен Норлатта бәлки урын табарга мөмкиндер? Бернигә карамастан шушы эшне яңадан торгызасы иде бит, иптәшләр!

Н. ФӘХРИЕВА.
Норлат шәһәре.

Башта колхозда төрле эштә йөрде, чөгендерче булды. Кышкы чорда исә терлекчелектә хезмәт куйды. Инде менә Суфия Ситдиковна Садретдинова соңгы биш-алты ел эчендә товарлыклы-сөтчелек фермасында бөтенләй үз кеше булып китте. Ул таналар карады, аларны саварга өйрәтте. Агымдагы елның сигез аенда Суфия Ситдиковнаның күрсәткечләре начар булмады. Ул һәр сыердан уртача 1910 килограмм сөт сауды. Бу күркәм уңышларга Суфия Ситдиковна әлбәттә, уңганлыгы һәм тырышлыгы нәтиҗәсендә иреште.

Рәсемдә: «Игенче» колхозының сыер савучысы С. С. Садретдинова.

ЯҢА ГАЗЕТА

Октябрь районында быел матбугатка язылу элекке еллардагыдан сүлпәнрәк бара. Хәер, бу республика күләмендә дә шулай. Ә яңа газеталарны алырга теләүчеләр бөтенләй аз. Татарстан ССР Югары Советының һәм Министрлар Кабинетының «Известия Татарстана» (татарча басмасы «Татарстан хәбәрләре») белән дә шундый ук хәл.

Моның төп сәбәбе—мөгаен, күпләр әле бу яңа басмалар турында бөтенләй белми дә. Шуңа күрә газета укучыларга аны тәкъдим итәргә телим. Газета Татарстан депутатларының ихтыяры, теләге белән туды. Алар Югары Советның беренче утырышында ук партия һәм совет матбугатын аеру турында сүз кузгаттылар. Мәгълүм булганча, республикада әлегә кадәр «Советская Татария» газетасы рус телендә бу органнарның уртак басмасы иде. Агымдагы ел башыннан ул КПСС рескомы органы булып кына калды. Аның базасында февраль аенда «Известия Татарстана»ның («ИТ») сынау саны чыкты. Ел азагына кадәр аның тагын берничә саны дөнья күрәчәк.

Газетаның баш редакторы, ТССР халык депутаты, Президент советы члены Юрий Алаев газетаны ничек итеп күз алдына китерә соң?

«ИТ» газетасы атнага биш мәртәбә ике басма табак күләмендә чыга. Ул Татарстанның җитәкче органнары эшчәнлеген киң яктыртучы, информациягә бай газета булачак. Сүз уңаеннан әйткәндә, газета хөкүмәт һәм республика президенты, парламент карарларын, яңа законнарны игълан итеп кенә калмыйча аларга компетентлы белгечләрнең аңлатма бирүен дә планлаштыра. Республика җитәкчеләренең һәм халыкның үзара элемтәсен чагылдыру максатында хатларны һәм откликларны, хәтта алар республика җитәкчелеген тәнкыйтьләсә дә, киң күләмдә биреп барачак.

Сәяси тема белән беррәттән, газета экономика мәсьәләләрен дә киң яктыртуны күздә тота. Союз һәм Россия милкен национализацияләү, приватизация, экономиканы дәүләттән аеру, куәтле хәрби промышленность комплексын конверсияләү, фермер, гомумән, авыл хуҗалыгының күп төрле укладлары торгызылу, базар экономикасы һәм башкалар—газета битләрендә даими чагылыш табачак темаларның кайберләре. Газета, әлбәттә, Татарстан суверенитетын гамәлгә ашыру юлларын яктыртуны да игътибар үзәгендә тота.

Газета нинди теманы гына яктыртса да, редакция өчен алгы планга халык мәнфәгате, аларның тормышын һәм хезмәт шартларын яхшырту, әхлакый һәм физик сәламәтләндерү мәсьәләләре көн үзәгендә торачак. Бәяләр күтәрелү сәбәпле күп гаиләләр газетаны чикле күләмдә алуын күздә тотып, редакция коллективы атнага бер дайджест бит чыгаруны планлаштыра. Анда укучылар үзәк басмаларның иң кызыклы язмалары белән таныштырлар.

Бер сүз белән әйткәндә, «Известия Татарстана» («Татарстан хәбәрләре») киң катлам укучыларга исәп тотып чыгарыла һәм ул республиканың башка басмалары белән ярышырлык булыр, аңа язылучылар әлеге басманы сайлауларына үкенмәсләр дип ышанабыз.

В. ДАНИЛОВ,
«Известия Татарстана» газетасының үз хәбәрчесе, ТССР халык депутаты.

Безнекеләр беренче

15 августтан 15 сентябрьгәчә «Игътибар,юлда —балалар!» айлыгы бара.

30 июльдән 22 августкача ТССР Эчке эшләр министрлыгының дәүләт автоинспекциясе Татарстан профсоюзларының республика Советы, халык мәгарифе министрлыгы, автоһәвәскәрләрнең бөтенсоюз ирекле җәмгыяте республика Советы, республикабызның Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай җәмгыяте, «Татавтотранс» ассоциациясе, «Динамо» Татарстан Советы белән берлектә юл хәрәкәте яшь инспекторларының республика лагерь сменасын оештырган иде. Сменаны оештыручылар юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча балалар белән эшләүнең нәтиҗәлелеген арттыру, тәҗрибә алмашу, тематик гомуми чаралар методикасына өйрәтүне үзмаксат итеп куйганнар иде. Монда безнең район исеменнән шәһәребезнең 4 нче мәктәбе базасында төзелгән отряд (җитәкчесе—В. С. Малыгин) чыгыш ясады һәм республика күләмендә беренчелекне яулады. Шәхси исәптә 4 нче мәктәпнең 8 класс укучысы Р. Мирзагалимов җиңүче булды.

Х. ӘЮПОВ,
ГАИ начальнигы, милиция капитаны.

Мини-әңгәмә

Гәйтән элемтә бүлекчәсе.

СОРАУ: Сездә район газетасына язылу нилектән сузыла?

Мария Семеновна Фомина, бүлекчә начальнигы.

Мин чираттагы ялда идем, шушы көннәрдә генә эшкә чыктым. Ләкин газета-журналларга язылуны үзвакытында төгәлләячәкмен дип ышандырып әйтә алам.

СОРАУ: Ә сезнең урында берәү дә эшләп торырга теләмәдеме?

М. С. Фомина: Людмила Нягукованы калдырган идем дә, ул минем вазифаны башкармаган. Аннан безнең бүлекчәнең үз почтальоны да юк.

СОРАУ: Хәзерге вакытта район газетасына күпме кеше язылды?

М. С. Фомина: «Дружба»га —25, «Туслах»ка —4. «Дуслык»ка—5.

ИСКӘРМӘ: Әлегә район буенча газета-журналларга язылуның барышы куандырырлык түгел. Моның сәбәбен, күпчелек элемтә бүлекчәләре начальникларының чираттагы ялда булуыннан күрергәме инде?!

Җирле матбугатны пропагандалаучылар газетаның һәрбер кеше өчен киңәшче дә һәм дус та булуын онытмасыннар иде. Язылырга ашыгыгыз, дуслар!

02 хәбәр итә

Районда мотоцикл урлау очраклары дәвам итә. Мәсәлән, 19 августтан 20 сенә каршы төндә билгесез кешеләр Андреевка авылында яшәүче П. В. Егоровның «Восход» мотоциклын (номеры 95—83 ТТГ) урлап чыгалар. 21 еннән 22 сенә каршы төндә Норлатта яшәүче В. И. Шубина хуҗалыгыннан «Минск» мотоциклы, 26 августтан 27 сенә каршы төндә Зөлкәрнәевләрнең гаражыннан «Иж-Планета-2» мотоциклы, 4 сентябрьдән 5 енә каршы төндә Ключи поселогында Усмановлар гаражыннан «Ява-350» мотоциклы урлана.

20 августта билгесез караклар Норлатта Октябрьская урамында яшәүче Морадыймовлар йортыннан әйберләр урлап чыгалар. Шул ук көнне МСО складыннан 1200 килограмм макарон оны урлануы хакында хәбәр алынды.

Хәзерге вакытта районда акча средстволарын һәм материаль байлыкларны саклау объектларын паспортлаштыру эше бара. Бу уңайдан ТССР Министрлар Советы карарында соңгы вакытта дәүләт милкен урлауларның 49,3 процентка үсүе турында әйтелә. Элеккечә үк, хуҗасызлык күренешләре, объектларның техник яктан канәгатьләнмәслек торышы җинаятьләр өчен уңай шартлар буларак хезмәт итәләр. Мисал өчен, соңгы вакытта МСОда берничә тапкыр ничә мең сумлык зыян китергән урлашу очракларын күрсәтергә мөмкин. Бу оешма җитәкчеләре киләчәктә дә шундый хәлләргә юл куймас өчен нинди дә булса чаралар күрергә тиешләрдер, ләбаса.

Акча средстволарын саклау буенча Кузнецов, Мичурин исемендәге,«Кондырча», «Ленинский путь» колхозлары һәм сөт-май комбинаты, НГДУ, УТТ, НГДУ ОРСы, Норлат станциясе депосы, РПО, урман промышленносте хуҗалыгы кебек предприятиеләр өстәмә чаралар күрсәләр бер дә артык булмас иде.

29 август көне шушы соңгы унбиш көнлектә иң фаҗигале көн дияргә дә мөмкин. Бу көнне кичен сәгать сигез тулып килгәндә Түбән Норлат авылыннан авыр хәбәр алынды. «Кондырча» колхозы фермасы янында Самара өлкәсенең Кошки районы «Степное Мамыково» колхозы комбайнчысы «Минск» мотоциклын бәрдерә. Нәтиҗәдә мотоцикл хуҗасы —11 нче класс укучысы Р. Дәүләтчаров шифаханәгә илткән вакытта вафат була. Ә күрше өлкә комбайны нишләп йөргән соң ул тирәдә диярсез, мөгаен. Комбайнчы Н. Әгълимов һәм аның ярдәмчесе Камалетдинов кырдан 3 капчык бодай урлап, шуны сату өчен Түбән Норлатка юл тотканнар икән. Хәзерге вакытта әлеге «сәрхүшләр» өстеннән җинаять эше кузгатылды.

Август ахырында Октябрь эчке эшләр бүлегенең тикшерү органнары тарафыннан уннан артыграк кешегә карата җинаять эше кузгатылды. 1 сентябрьдә Түбән Норлат авылында Ф. Әхмәдиевне кыйнаган һәм Хәмәтовлар хуҗалыгында тәрәзә пыялалары ваткан Х. Х. Рәхмәтуллин һәм И. Д. Юнысов та бар бу исемлектә. Моннан тыш, Төрнәстән С. Колотухин һәм Совет Армиясе сафларыннан ялга кайткан хәрби хезмәткәр И. Нәфыйгов та шул ук язмышка дучар. Чөнки алар 3 сентябрь көнне базарда алма сатучы Андрух исемле кесәсене куркытып, аның акчасына хуҗа булырга ниятлиләр. Әмма акча аларга насыйп булмаган икән, егетләр милиция хезмәткәрләре тарафыннан тотылдылар.

Соңгы вакытта шикәрчеләр поселогында яшәүчеләрдән телефон аша милициягә хәбәр алынды. Кешеләр дачалар территориясендә ниндидер бер шикле ир-атның йөрегәнен әйтәләр. Оперуполномоченный В. И. Чернышев һәм участок инспекторы Г. Ф. Чуркинның оста һәм кыю эш итүләре нәтиҗәсендә 5 сентябрьдә әлеге шикле кеше тотылды. Ул элек тә хөкем ителгән, хәзерге вакытта эзләнелә торган Р. В. Бильданов булып чыкты. Хәтерләсәгез «02 хәбәр итә» дигән язмаларыбызның берсендә без август аенда Дружба урамында яшәүче Сафиуллиннар фатирыннан магнитофон кассетасы һәм шоферлыныклыгы урлаганлыгы хакында әйтеп узган идек. Әлеге җинаятеннән соң ул качкан иде һәм шул арада янә дә җинаятьләр эшләп өлгерде. Инде менә ул кулга алынды һәм лаеклы җәзасын көтә.

Р. ТӘМАЕВ,
милиция капитаны.

ПЕШЕРЕП КАРАГЫЗ ӘЛЕ

ЧӘКЧӘК. Савытка йомырка сытып, сөт, тоз, шикәр комы өстәп, әйбәтләп туглыйлар да йомшак кына итеп камыр басалар. Аны вак кисәкләргә бүлеп, 1см калынлыктагы бау сыман тәгәрәтәләр дә эрбет чикләвеге кадәр итеп кисәләр, кызган майга салып, алтынсу төскә кергәнче пешерәләр. Пешергәндә болгатып торырга кирәк.

Икенче савытта балга шикәр комы салып кайнаталар. Аның әзер булу-булмавын белү өчен, шырпы белән бер тамчы бал алалар, шырпыдан агып төшкән бал сынса, әзер була. Моны балкашык белән бал алып, салкын суга тамызып карап та беләләр. Бал шар кебек булып катып китсә, җәелмәсә, ул әзер була. Балны озак кайнатырга ярамый, көеп каралып китеп, чәкчәкнең тәмен дә, төсен дә бозуы мөмкин.

Әзер төшне зур савытка бушаталар, өстенә бал салып, әйбәтләп болгаталар, аннары чәкчәкне подноска яки тәлинкәгә салалар, кулны салкын суга тыгып алып, чәкчәккә теләгән форма бирәләр. Чәкчәкнең өстен бизиләр.

Телевидение

ШИМБӘ
14 СЕНТЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

16.55 «Ералаш» киножурналы.
17.05 Варисларда кунакта.
17.40 Т. Миңнуллин.«Без китәбез, сез каласыз». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Әлли-бәлли-бәү».
19.40 «Без китәбез, сез каласыз» спектакленең дәвамы.
20.55 Өлкәннәр өчен мультфильм.

I ПРОГРАММА

6.30 Концерт.
7.05 Мультфильм.
8.00 Ритмлы гимнастика.
8.30 «ТЯХ».
8.45 Концерт.
9.25 «Бурда моден» тәкъдим итә...
9.55 Иртәнге күңел ачу программасы.
11.40 Алтын тире.
12.00 Шагыйрь кызы.
12.30 Н. Гнатюк җырлый.
13.15 Партнер.
13.45 «Свифт төзегән йорт». 1 серия.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Свифт төзегән йорт». 2 серия.
16.20 «Җир—уртак йортыбыз».
16.25 «Чаң».
17.40 Концерт.
17.45 Державаның мәңгелек мәхәббәте.
18.35 «Бал корты Майя». 12 серия.
19.00 Футбол. СССР чемпионаты.
19.50 Халык моңнары.
20.00 «Карив сере». Нәфис фильм. 1 серия.
21.00 «ТЯХ».
21.40 «Карив сере». 2 серия.
22.40 «ТЯХ».
23.00 «Бер актер театры». Е. Шифрин.
00.30 «Ганлә» атналыгы хитпарады.
01.45 «Клоун». Нәфис фильм. 1 серия.
02.55 Док. фильм.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Футбол. СССР чемпионаты. Торпедо—ЦСКА. 2 тайм.
9.05 Спорт—һәркем өчен.
9.20 Мультфильм.
9.30 «Хезмәттәшлек» видеоканалы.
11.00 «Плюс унбер» видеоканалы.
13.00 «Ролан Гарро ритмнары». Теннис буенча Франциянең ачык чемпионаты.
13.45 Күп серияле фәнни-популяр фильм. 1серия.
14.40 Коллаж.
14.45 Сәяхәтчеләр клубы.
15.45 Спорт гимнастикасы.
21.45 «Столица» журналын презентацияләү.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 «А» программасы.
00.40 Волейбол. Европа чемпионаты. Ирләр.

ЯКШӘМБЕ
15 СЕНТЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.45 Керәшен татарларының фольклор коллективлары чыгышы.
18.30 «Панорама» информацион программасы.
19.30 «Татарстан урманнары». Урманчылар көненә карата.

I ПРОГРАММА

8.00 Ритмлы гимнастика.
8.30 «ТЯХ».
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 Безнең бакча.
9.15 Иртән иртүк.
10.00 Ватанга хезмәттә.
11.00 Таң йолдызы.
12.00 Сәяхәтчеләр клубы.
13.00 Авыл сәгате.
14.00 Марафон-15.
15.00 «ТЯХ».
15.15 Хоккей. Канада кубогы. Финал.
17.15 Халыкара панорама.
18.00 «Тавышлар күп — дөнья бер тенә».
18.10 Уолт Дисней күрсәтә.
19.00 Док. фильм.
19.35 «Икенче талпыныш». Нәфис фильм.
21.00 Информацион программа.
21.40 «Брейн ринг».
22.15 Спорт программасы.
0.35 Волейбол. Европа чемпионаты.
01.35 «Клоун». Нәфис фильм. 2 серия.
02.55 Концерт.

II ПРОГРАММА

8.00 Күнегүгә басыгыз.
8.15 Халык моңнары.
8.30 Спорт гимнастикасы.
9.30 «Хезмәттәшлек» видеоканалы.
11.00 Фил Донахью программасы.
12.05 Док. фильм.
12.15 Балалар өчен программа.
15.50 «Кызыл кояш». Нәфис фильм. (АКШ).
17.05 Мультфильм.
17.25 «Тану».
20.30 Түгәрәк өстәл.
22.00 К-2 тәкъдим итә.
22.45 Ирекле комментарий.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Росмузимпорт.

Ышанып тапшырдылар.

01 хәбәр итә

1 августтан 1 сентябрьгәчә чорда районда 2 янгын очрагы булды.

2 августта Норлатта М. Т. Әбделманов хуҗалыгында янгын чыкты. Янгын чыгуга балаларның шырпы белән уйнавы сәбәпче булды. Нәтиҗәдә ишегалдындагы корылмалар янып бетте.

1 сентябрьдә Норлатта яшәүче Җәббаровлар хуҗалыгында да янгын чыкты. Нәтиҗәдә торак йорт һәм ишегалды корылмалары кара күмергә әйләнде. Әлеге янгын очрагы буенча тикшерү бара.

Ә. ӘЮПОВ,
дәүләт янгын сакчылыгы бүлеге инспекторы.

МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.

Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 109. Тираж 3413.